Килешенде ____________
Әтнә районы Башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" казна учреждениесе җитәкчесе
Р.Р.Фатыхов

Раслыйм: ____________
Әтнә районы "Мәктәптән тыш эшләр үзәге" өстәмә белем бирү учреждениесе директоры
М.Н. Гарипова

Килешенде: ____________
"Әтнә таңы" газетасы редакторы
Г.Р.Мухаметзянова

Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган
"БАРЫСЫ ДА ХӘТЕРДӘ!"
районара "Яшь журналист" конкурсы
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**1.Төп нигезләмә**

1.1. Районара яшь журналистлар конкурсы (Конкурс) Әтнә районы мәгариф бүлегенең Бөек Җиңүнең 80 еллыгын каршылау уңаеннан төзелгән план нигезендә эшләнә. Нигезләмә Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртипләрен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – Әтнә районы "Мәктәптән тыш эшләр үзәге" өстәмә белем бирү учреждениесе.

**2. Конкурсның иаксаты һәм бурычлары**

2.1. Максат: укучыларны сугыш чоры вакыйгалары турында эзләнү эшенә тарту.

2.2. Бурычлар:

- әдәбият һәм сәнгатькә сәләте булган укучыларны ачыклау, аларга иҗади яктан үсүдә һәм камилләшүдә ярдәм күрсәтү;
- эстетик зәвык һәм әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- укучыларга сугыш чоры турында күбрәк мәгълүмат тупларга булышу;
- туган ягыбыз тарихы белән таныштыру;
- укучыларның игътибарын рухи мирасыбызны өйрәнүгә юнәлтү.

**3. Конкурсның катнашучылары**

3.1. Конкурста 7 яшьтән 18 яшькә кадәр булган укучы балалар катнаша ала.

3.2. Конкурс түбәндәге яшь төркемнәре арасында үткәрелә:

- 7-10 яшь
- 11-13 яшь
- 14-18 яшь

**4. Конкурсның номинацияләре**

4.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

- шигърият (шигырь, поэма...)
- чәчмә әсәр (публицистика, инша, эссе...)
- интервью (сугыш чоры балалары, тыл батырлары, сугышта булучыларның балалары белән әңгәмә)
- рәсем (Бөек Ватан сугышы, Бөек Җиңүне тасвирлаган рәсемнәр)
- фотоколлаж (Бөек Ватан сугышы һәм шул чордагы тыл тормышын тасвирлаган фотолардан төзелгән тематик коллаж)

**5. Конкурсның үткәрелү вакыты һәм куелган таләпләр**

Конкурс эшләре түбәндәге таләпләр буенча 2025 елның 1 февраленнән башлап 14 майга кадәр rita.sabir@mail.ru электрон почтасына кабул ителә. Эшләрне почтага “Яшь журналист конкурсы” темасы белән салырга.

- Конкурска язма эшләр татар телендә һәм рус телендә кабул ителә;
- **Чәчмә әсәрләр, интервьюлар, шигъри әсәрләр** А4 форматта (шрифт 14, Times New Roman, юлара интервал –одинарный. Як-яктан кырлар – 2-1.5 см., өстән - 2см, астан - 2 см. киңлектә калдырырга). Күләме ярты биттән ким булмаска һәм 2 биттән артмаска тиеш;
- шигъри язмалар кәгазь битенең сул ягы буенча тигезләнә. Чәчмә әсәрләр кәгазь битенең киңлеге буенча тигезләнә;
- язманың исеме уртада ярымкалын шрифт белән күрсәтелә;
- язма ахырында авторның тулы исеме, фамилиясе, укыган мәктәбе, сыйныфы, тулы яше, язма эшне башкарырга булышкан җитәкченең (әгәр булса. Укучы эшне үзе генә дә башкарырга мөмкин) Фамилия һәм инициаллары языла.
- **рәсемнәр** А3, А4, А5 форматта булырга мөмкин. Як-якта буш кырлар калдыру мәҗбүри түгел. Техникасы – ирекле (карандаш, гуашь, акварель...). Рәсемнең аскы ягына таблица формасын тутырып ябыштырырга (шрифт 12, Times New Roman, юлара интервал –одинарный)

| | |
|---|---|
| Исеме | “Минем әбием –тыл батыры” |
| Автор | Галиева Гөлия |
| Тулы яше | 12 яшь |
| Мәктәбе, сыйныфы | Әтнә районы Куәм урта мәктәбе 5 сыйныф |
| Җитәкчесе | Валиева А.Б. |

Рәсемнәрне, таблицаны ябыштырганнан соң, сканировать итеп җибәрергә. Тигез һәм яхшы сыйфатлы фото итеп җибәрергә була. Сыйфатсыз фотолар кабул ителми.

**-фотоколлажда** күрсәтергә теләгән фикерне 1-2 җөмлә яки шигъри юллар белән бирергә була. Аерым язмада фотоларның тарихын, кемнәр, кайсы чор күрсәтелгәнен аңлатып язып җибәрергә.

**6. Конкурс эшләрен тикшергәндә игътибар ителә торган критерийлар:**

- Конкурс эшләре моңарчы башка матбугатта басылмаган, башкалардан күчерелмәгән булырга тиеш;
- Эшләрнең оригинальлегенә өстенлек бирелә;
- Эшләр хатасыз, куелган таләпләргә туры килгән булырга тиеш;
- Теманың ачылышына, тарихи фактларга, эзләнүләргә бай булуына өстенлек бирелә;
- Язмаларны фото фактлар белән баетып бирү хуплана.

**7.Конкурска нәтиҗәләр һәм жюри**

Конкурс эшләре Әтнә районы укучыларының “Мәктәп” газетасы һәм “Әтнә таңы” газетасы битләрендә чагылдырып барылачак.

Конкурс эшләрен Әтнә районы “Мәктәптән тыш эшләр үзәге” оешмасы “Журналистика” берләшмәсе җитәкчесе җыя. Эшләргә нәтиҗә 2025 елның 15 май числосында “Әтнә таңы” редакциясе хезмәткәрләре белән берлектә ясалачак. Һәр номинациядә яшь төркемнәре буенча 1,2,3 урыннар билгеләнә. Аларга Җинүче дипломнары һәм барлык катнашучыларга Катнашучы сертификаты биреләчәк.

Белешмәләр өчен элемтә:

Тел. 89520361781 - Садриева Рита Ришатовна